ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ЯМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423753, Татар Ямалы авылы,
Ленин ур.,6 нчы йорт.
Тел.:(85552)3-44-58; .
E-mail: tyamal-akt@yandex.ru

СОВЕТ ТАТАРСКО-ЯМАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423753, село Татарские Ямалы,
ул.Ленина,дом 6.
Тел.:(85552)3-44-58; .
E-mail: tyamal-akt@yandex.ru

КАРАР — РЕШЕНИЕ

21.11.2023ел — №18

Актаныш муниципаль районының "Татар Ямалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Актаныш муниципаль районының "Татар Ямалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Прокурорның 30.06.2023нче елгы 02-08-02-2023 номерлы протестын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2022 №90-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 10.07.2023 № 286-ФЗ Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Актаныш муниципаль районының "Татар Ямалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Актаныш муниципаль районының "Татар Ямалы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә , Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Советының 2015 елның 10 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган (2018 елның 5 июлендәге 20 номерлы үзгәрешләр кертелгән):

1.1. 16 нчы пунктның икенче абзацында "яисә алар тарафыннан тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүматлар тәкъдим итү" дигән сүзләрне "үз чыгымнары турында белешмәләрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган мәгълүматларны белә торып тапшыру, яисә дөрес булмаган мәгълүматларны белә торып тапшыру" дигән сүзләр белән алыштырырга , “яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматны тәкъдим итмәү яки тәкъдим итү " дигән сүзләрне “яки федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирмәү, тулы булмаган мәгълүмат бирү яки хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында дөрес булмаган мәгълүмат бирү” дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 6 нчы пунктының «в» пунктчасында һәм 13 нче пунктында "акцияләр" сүзен алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "Татар Ямалы авыл җирлеге"бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татар Ямалы авыл жирлеге башлыгы: Д.Ф.Валиев